ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37
йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№** 3 2023 елның 31 гыйнвары

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында 19.11.2022 ел №1, 19.11.2022 ел №2, 26.11.2022 ел №3, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының кушымта итеп бирелгән үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарылырга һәм ул Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов

ИНН 1642004868

Кушымта 1
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына
31.01.2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнарның гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2023елның 1 гыйнварыннан 20 мартына кадәр срокта түләнә.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) көндезге формада укучы студентлар;

б) I төркем инвалидлар;

в) Бөек Ватан сугышында катнашучылар;

г) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары;

д) Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр

4. Түбәндәге игътибарга лаек сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт булмау,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә, өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерүнамә) бланкы мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кую яки почта элемтәсе чарасына юллау юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша акча күчерү юлы белән Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша башкарыла.

8. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма
комитетының карарына
31.01.2023 ел № 3

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А
_____________________________________________________________
Адресы: _______________________________________________________
_____________________________________________________________
нигезендә, Сезгә ________ елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен ______ сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО
Назначение платежа

Җитәкче __________________ ________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № _________________
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча_________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и. ________________________________________________________
Адресы:
_____________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ елда
_______________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*